**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Азнакай районының Балан-Бүләк авылы;
Биектау районының Каракүл авылы;
Саба районының Мәртен авылы;
Саба районының Өчнарат авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Азнакай районының Илбәк авылындагы Профсоюз урамы;
Саба районының Олы Арташ авылындагы Күпер урамы;
Саба районының Төбәк авылындагы Яшьләр урамы;
Сарман районы Иске Кәшер авылының Комсомол урамы;
Спас районының Болгар шәһәрендәге Назаровлар урамы;
Спас районының Татар Такталысы авылындагы Зәйдуллин урамы;
Теләче районының Теләче авылындагы Елга аръягы урамы;
Казан шәһәренең Северный торак массивындагы Смоленская урамы;
Казан шәһәре Магистраль урамындагы 18 А номерлы йортның өй яны территориясе.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 22 июнендәге ПУ-572 номерлы Указының 1 пунктындагы «а»

пунктчасының икенче һәм дүртенче абзацларын, «б» пунктчасындагы икенче, дүртенче, бишенче һәм алтынчы абзацларын;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Сарман районының аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 24 июнендәге ПУ-588 номерлы Указын;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 26 июнендәге ПУ-598 номерлы Указын.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 28 август
№ ПУ-812